12+

# Мөселманнар

ГАЗЕТАДА КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, АНЫ ТИЕШСЕЗ МАКСАТЛАРДА КУЛЛАНУДАН САКЛАНЫГЫЗ

№5 (149) май, 2017
шәгъбан – рамазан-1438



## «Балаларга яхшы тәрбия бирсәк, бәрәкәте барчабызга да булачак»

**Чирек гасыр элек Чаллыда, Яңа шәһәрнең 2 нче комплексындагы ташландык балалар бакчасы бинасында ачылган Ак мәчет башта Мәрҗани исемен йөртә. Дүрт ел Рәфкать хәзрәт Харрас имам-хатыйблык иткәннән соң бу вазыйфа Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиевкә күчә. Шул елны Аллаһ йорты исемен алыштыра.**

**«Ак мәчет» мәдрәсәсе исә башта кызлар өчен ачылган, Тәнзилә абыстай хөрмәтенә ул аның исемен йөрткән. 2000 елда Диния нәзарәте карары белән ул ир-егетләр мәдрәсәсе итеп үзгәртелә. Уку йорты бүгенге көндә имам-хатыйблар, ислам дине нигезләре һәм гарәп теле буенча укытучы-мөгаллимнәр әзерли.**

▶▶▶ 5 бит

Татарстанда язылу индексы – П3131

# Татарстан мөселманнарының VII корылтае узды

**Казанның «Корстон» мәдәни-күңел ачу комплексында Татарстан мөселманнарының VII корылтае узды. Аның эшендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов, Татарстан Республикасы Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев һәм республика дин әһелләре катнашты.**



*ТР мөселманнары Диния нәзарәте составына 1415 мәхәллә һәм 1430 мәчет керә. Анда 1400 гә якын имам хезмәт куя. Соңгы дүрт елда Татарстанда 50 дән артык яңа мәчет ачылган*

Корылтайда Татарстан Республикасы Диния нәзарәте рәисе, мөфти сайланды. Әлеге вазыйфаны янә Камил хәзрәт Сәмигуллин башкарачак. Делегатлар шулай ук ачык тавыш бирү юлы белән мөфтинең беренче урынбасарын, баш казыйны сайлады. Баш казый вазыйфасына Җәлил хәзрәт Фазлыев кандидатурасын якладылар. Камил хәзрәт Сәмигуллин беренче урынбасары вазыйфасына Рөстәм Вәлиуллинны тәкъдим итте, делегатлар аны хуплады.

Рөстәм Миңнеханов корылтайда катнашучыларга мөрәҗәгать итеп, соңгы 4 елда республикада зур гына үзгәрешләр булуын, шул исәптән ислам дине дөньясында да үзгәрешләр күзәтелүен билгеләп үтте. «Республикада тынычлык хакимлек итә, шулай булгач, алга таба ниятләнгән планнарны тормышка ашырырга бөтен мөмкинлекләр бар. Диния нәзарәте бу юнәлештә үзеннән зур өлеш кертә, – дип Президент хөкүмәт исеменнән, шәһәр һәм район башлыклары исеменнән дин әһелләренә рәхмәтен җиткерде. – Киләчәктә дә шулай бергә кулга-кул тотынып эшләрбез дип уйлыйм».

Республика җитәкчесе имамнарны әзерләүгә зур игътибар бирелүен билгеләп узды. «Без Болгар ислам академиясенә зур өмет баглыйбыз. Төзелеш эшләре тәмамлангач, бу академия Татарстан, Россия мөселманнары өчен уку йорты гына түгел, ислам динен саклый торган бер үзәк булачак», – диде.

Рөстәм Миңнеханов янә мөфти булып сайланган Камил хәзрәт Сәмигуллинның яхшы эшен, күп кенә яңалыклар кертүен ассызыклады һәм болай диде: «Әлбәттә, эшлисе эшләребез күп. Мин ышанам: әгәр бүген без мөфтигә ышанып тавыш бирәбез икән, республика тарафыннан бөтен көчне куеп ярдәм итәрбез. Киләчәктә дә Татарстан Россиянең тыныч төбәге булып калырга тиеш».

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе булып сайланган Камил хәзрәт Сәмигуллин, 2013-2017 елларда мөфти вазыйфасында башкарган эшләре турында хисап тотты һәм алда торган бурычларны бәян итте:

– Бүгенге заман мөселманы үзенең тормышын мәчеткә йөрү белән генә чикләми. Аның үз кызыксынулары бар, ул гаилә планлаштыру үзәкләренә, фитнеска, ресторанга, мәктәпләргә, балалар бакчаларына йөри. Шуңа күрә республикада мөселманнар өчен уңайлы мохит тудыруны максат итеп куйган «Тормыш рәвеше буларак ислам» дип аталган проект эшләнде һәм аны тормышка ашыра башларга вакыт җитте. Моннан тыш, безнең алда өстенлекле булып түбәндәге мәсьәләләр дә торырга тиеш: татар дин галимнәренең хезмәтләрен өйрәнүне дәвам итү һәм укыту программаларына кертеп җибәрү; татар дини-фәнни мәктәбен торгызу; уку-укыту программаларын һәм материалларын стандартлаштыру; милли үзаңны һәм телне саклау; Коръәнне татар һәм рус телләренә кануни тәрҗемә итү. Әлеге нәтиҗәләргә ирешү өчен:

– милләткә рухи-әхлакый юнәлеш бирә алырлык, тирән белемле татар дин белгечләрен һәм мөселман зыялыларын тәрбияләргә кирәк. Татарстан Республикасы ислам мәгарифе дәрәҗәсен үстермичә моңа ирешү һич мөмкин түгел;

– имамнарның җәмгыятьтәге абруен күтәрмичә дә без максатларыбызга ирешә алмаячакбыз. Имамнарга һәм аларның ихтыяҗларына йөз белән борылырга, үз араларында һәм өммәттә теләктәшлек тәрбияләргә, хокукларын якларга кирәк;

– мөселман дин әһелләренең кадрлар резервын туплау. Бу өлкәдәге концептуаль документларны эшләүгә якын киләчәктә үк керешергә кирәк.

Алга таба мөфти хәзрәт, дөрес һәм уйлап корылган мәгълүмати сәясәт безгә киң җәмәгатьчелеккә исламның асыл кыйммәтләрен җиткерергә, татар рухи мирасын сакларга, экстремизмга каршы торырга мөмкинлек бирәчәк, дип билгеләп үтте һәм Гомумроссия ислам телевизион каналын булдыруның көнүзәк мәсьәлә булуын әйтте. «Әлеге медиапроект рухи-әхлакый кыйммәтләрне, Россиядә яшәүче мөселман халыкларының милли мәдәниятен популярлаштырырга ярдәм итә алыр иде», – диде ул.

Соңыннан Камил хәзрәт Сәмигуллин Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандартлар комитеты, «Вакф» фонды, «ДУМ РТ Хаҗ» операторы хезмәтләренә бәя бирде, алар алдында торган бурычларга тукталды.

– Мин үз чыгышымда Диния нәзарәте алдында торган төп проблемаларны ачып бирергә тырыштым. Иманым камил: татар мөселманнары, гаять бай рухи мирасыбызга һәм дини мәгариф системасының күп гасырлар дәвамында тупланган тәҗрибәсенә таянып, якындагы киләчәктә Россия рухи даирәсе үсешенә үзенең саллы өлешен кертәчәк әле. Татарстан Диния нәзарәте тырышлыгы белән ул бөтендөнья мөселман җәмгыятенең югары бәясен дә алыр, иншаллаһ! – дип тәмамлады үзенең чыгышын мөфти хәзрәт.

# Истә, һаман да истә...

**Берәр бәйрәмгә җыелыша башласак, Хатип абыйга хәбәр салынды микән, дигән уй килә. Аның юклыгы белән һаман килешеп булмый әле. Бәйрәмнәрдә дә, җомгаларда да гел безнең арада кебек.**



Сәламәтлеге какшап, кызы белән кияве йортына – Тынычлык бистәсенә күченгәч тә, мәчет белән арасын өзмәде, такси яллап килеп төшә торган иде. Ишегалдына аяк басуга, мәчет бинасына тагын бер тапкыр сокланулы караш ташлап ала. Эченнән генә: «Аллаһ рәхмәте белән, тәки булдырып чыктык бит, Азино халкын мәчетле иттек. Инде безнең халык та форсатны кулдан ычкындырмасын, намазга йөрсен, ислам гыйлемен алырга ашыксын», – дип уйлады микән?

... Мәчетебезнең беренче имамы, мәчет төзелешенең башында торган Хатип хәзрәт Бикмөхәммәтов узган елның



23 апрелендә бакыйлыкка күчте. Якыннары, мәхәлләдәшләр, быел шул көнне мәчеттә Коръән мәҗлесенә җыелып, аның рухына дога кылдык. Ачык йөзле, яхшы күңелле, ихлас кеше иде Хатип абзый. Рухы шат, урыны җәннәттә булса иде.

# Исеме җисеменә туры килсен, дип тырышабыз

**Мәчетебезне Казан каласында гына түгел, республикабызда белмәгән кеше юктыр. Шулай да еш кына: «Хәзрәт, сезнең мәчеттә никах укыйлармы? Никах тантанасын уздырырга мөмкинлекләр бармы?» – дигән сораулар белән мөрәҗәгать итәләр. Аллаһының рәхмәте белән безнең мәчет Гаилә дигән исемне йөртә. Һәм без һәрвакыт мәчетнең исеме җисеменә туры килсен дип тырышабыз.**

Гаилә ул никахтан башлана. Безнең Гаилә мәчете күп гаиләләрнең тууына сәбәпче булды, бик күп никахлар укылды, Аллаһы Тәгалә аларның никахларын бәхетле, бәрәкәтле кылса иде. Әмма мөселманнар арасында да пар табу, гаилә кору проблемасы бар. Шуны күздә тотып, без мәчет каршында таныштыру үзәге ачып җибәрдек (тел.: 89370021074; 89375211928). Үз парын тапканнар, инде никах-туй хәстәре белән йөрүчеләр дә һич шикләнмичә туп-туры безгә килә ала. Никахын да укырбыз, тантанасын да истә калырлык итеп уздырырга ярдәм итәрбез. Банкетлар, мәҗлесләр уздыру өчен безнең мәчеттә 30 һәм 100 кунакка исәпләнгән ике зал бар. Һәр гаилә залны үз матди мөмкинлегеннән чыгып сайлый. Мәчетебездә кухня эшли, теләгән хуҗабикәләр шул кухняда пешереп, мәҗлес табынын үзе әзерли ала. Әмма бәйрәм көнне күпләр, пешерү мәшәкатьләрен профессионалларга тапшырып, үзләре табын артында бәйрәм итү ягын карый. Ул очракта безнең кызлар сезгә ярдәмгә килергә әзер.

Никах – һәр гаиләнең тормышында бик зур вакыйга һәм аның һәр мизгелен истә калдырасы, еллар узгач та хәтердә яңартасы, хатирәләрне балалар, оныклар белән бүлешәсе килә. Еш кына миннән: «Хәзрәт, никах күренешләрен фотога төшерергә ярыймы?» – дип сорыйлар. Видеога һәм фотога төшерергә рөхсәт ителә. Кирәк булса, без сезгә ышанычлы фотограф һәм видеооператорлар белән элемтәгә керергә ярдәм итәрбез.

Гаилә мәчетендә мөселман кибете эшли, никах күлмәкләре, яулык, түбәтәй кебек никах өчен кирәк-яракны шул кибеттә сатып алырга була. Кәләшне шәригать кануннарына туры китереп киендерү, матур итеп яулык бәйләү өчен стилистлар чакырту мөмкинлеге дә бар.

Тормыш бер агымга тигез генә бармый, кайчак сикәлтәләргә дә юлыгасың һәм яшь парлар мондый сынауларга әзер түгел. Шуны күздә тотып, без мәчеттә Гаилә дәресләре алып барабыз. Ул дәресләрдә ир – хатын, килен – кайнана мөнәсәбәтләренә, бала тәрбияләү мәсьәләләренә кагылышлы сораулар күтәрелә.

Әбәби алып кайткан бәхетле әтиәниләрне без Гаилә мәчетенә исем кушу йоласына чакырабыз. Имамнарыбыз нарасыегызга шәригатькә туры килгән, матур мәгънәгә ия булган исем сайларга ярдәм итәр. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен исә мәчетебездә ислам нигезләрен өйрәтүче төркем эшләп килә. Мәчет ишегалдында заманча балалар мәйданчыгы төзеп куйдык. Нинди милләттән, диннән булуларына карамастан, шәһәрдәшләребезне гаиләләре белән шул мәйданчыкта ял итәргә чакырабыз.

Гаилә мәчете һәркайсыгыз өчен ярдәмкиңәш кирәк булганда, шатлык бүлешү яки күңел тынычлыгы табу өчен йөгереп килә торган; туган йорттай газиз бер сыену урыны булса иде.

Мәчетебезнең адресы: Казан ш., Җ.Фәйзи ур., 2; тел.: **8 (843) 223-06-62.**

Изге догалар белән
**Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН,**
ТР мөфтие урынбасары,
Гаилә мәчете имам-хатыйбы





# Мөселман балалар бакчалары яшәргә хокуклымы?

**«Мөселман гаиләләрендә туган балаларга исламча тәрбия бирүче бакчалар кирәк. Вөҗдан ирекге турында законы булган дәүләт теләгән кешегә укыту-тәрбия учреждениеләрендә дә дини тәрбия алу мөмкинлеге тудырсын иде. Бу – безнең ихтыяҗ». Күптән түгел Казанның Гаилә мәчетендә ТР Президенты эчке сәясәт департаменты һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белгечләре; республиканың мөселман балалар үзәкләре җитәкчеләре катнашында узган түгәрәк өстәл сөйләшүендә яңгыраган төп фикер шушы булды.**

Ислам дине буенча тәрбия бирә торган бакча ачарга мөмкинме? «Мөмкин, әмма балаларны намаз укырга өйрәтергә ярамый. Ә программада бары тик «Әхлак дәресләре», «Татар халкының милли гореф-гадәтләре» кебек дәресләр генә була ала, – ди менә инде 4 ел Яшел Үзән шәһәре мәдрәсәсе каршында эшләп килүче «Гөлбакча» балалар үзәге тәрбиячесе Миләүшә Зәйнуллина. – Эш башлаганда без үзебезгә аерым бер программа төзербез, үзебезчә эшләрбез дип уйлаган идек. Әмма тора-бара Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы тәкъдим иткән программадан башка эшләп булмаячагы ачыкланды».

«Программаның 60 проценты мәҗбүри, ә 40 проценты вариатив, ягъни үзгәрүчән. Без әнә шул өлешне милли-төбәк компоненты буларак кулланабыз һәм әхлак дәресләренә багышлыйбыз, – дип үз тәҗрибәсе белән уртаклашты Казанның «Нурлы» балалар үзәге мөдире Мәрьям Фатыйхова. – Әти-әниләр, әлбәттә, бездән күпне көтә. Татарча да, гарәпчә дә өйрәнсен, динне дә белсен…»



Балтач үзәк мәчете имамы Рамил Бикбаев инде 9 ел буе мәчет каршында эшләп килүче кыска көнле «Әс-сәлам» балалар үзәген җитәкли. «Атна дәвамында иртәнге 9 дан көндезге сәгать 12 гә кадәр 20 бала тәрбияләнә. Шимбә һәм ял көннәрендә 35 бала дин дәресләрен өйрәнергә килә. Минем уемча, мәчетләре, мәдрәсәләре, Россия ислам институты һәм Болгар ислам академиясе булган республикада балалар бакчасында да дин сабаклары укытылырга тиеш. Пәйгамбәребез (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм) кушуы буенча да бала 7 яшенә җиткәндә инде намазын торгызган була, кыска сүрәләрне яттан белә. Без үз динебезне кача-поса түгел, ә ничек тиеш – шулай өйрәтергә хокуклы», – ди Рамил хәзрәт.

«Моңа ирешергә мөмкин», – дип сүзгә кушылды Россия ислам институтының уку-укыту бүлеге җитәкчесе Нәзирә Гыйззәтуллина. – Булган тәҗрибәдән чыгып бер уртак укыту-тәрбия программасы төзергә, аны куллануга Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан рөхсәт – лицензия алырга кирәк. Россиянең Вөҗдан иреге турындагы законы нигезендә, Диния нәзарәте кабул иткән һәм рөхсәт иткән программалар балаларга тәрбия бирүдә кулланыла ала». Ә әлегә Татарстанда дәүләт лицензиясе булган, Диния нәзарәте учредительлегендәге бер генә мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе дә юк.

Сөйләшүне оештырган Татарстан мөфтие урынбасары, Гаилә мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин да бу ихтыяҗны дәүләт дәрәҗәсендә хәл итү кирәклеген аңлатты. «Балаларыбызны кечкенәдән үзебезнең дини традицияләргә таянырга өйрәтсәк, төрле агымнарга, радикализмга иммунитетыбыз шул булыр», – ди ул.

**Нәзирә РӘХМӘТУЛЛИНА,**
«Мәдәни җомга»

# «Балаларга яхшы тәрбия бирсәк, бәрәкәте барчабызга да булачак»

Гомумән, Чаллы мөселманнары активлыклары, яңалыкны эләктереп алырга торулары, кызыксынучан булулары белән аерылып тора. «Нинди гамьнәр белән, ни хәлләрдә яшәп ятасыз?» – дигән сорауны без Чаллы төбәге мөселманнары җитәкчеләренең үзләренә юлладык.



**Әлфәс хәзрәт ГАЙФУЛЛИН,**
Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе:

– Балаларга физик яктан да, тәрәккый яктан да көчле тәрбия бирә алсак, иншаллаһ, аның бәрәкәте барчабызга да булачак. Шәһәребездәге 14 мәчетнең һәрберсе ай саен зур бер чара уздыра. Ислам дине нигезләре буенча викторина, Коръән, намаз бәйгеләре, спорт чаралары на аеруча игътибар бирәбез. Безнең шәһәрдә «Хәзинә» балалар клубы бар, анда мәктәпкәчә яшьтәге мөселман балаларына өстәмә рәвештә дини тәрбия дә бирелә.

Мөселман яшьләренә шөгыль җитми – без инде моны күптән аңладык. Алар кирәкмәгән чараларга, дискотека-мазарга йөрми бит. Шуңа күрә буш вакытларын файдалы итеп оештырырга кирәк. Яшьләребез төрле спорт секцияләренә йөри. Футбол, хоккей, волейбол буенча хәтта һәр мәчетнең үз командасы бар. Көрәшәбез, кышын чаңгы ярышлары уздырабыз. Спорт мөселман кешегә ни бирә инде ул, диючеләр бар. Спорт ул дуслаштыра, ул бәрәкәт бирә.

*Сүз уңаеннан, апрель аенда Яр Чаллыда Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте кубогына татарча көрәш һәм кул көрәше буенча IX мөселман яшьләренең берләшкән турниры узды. Ярышларда республиканың 19 районыннан һәм якын төбәкләрдән – Башкортостан, Оренбург һәм Киров өлкәсеннән 100дән артык спортчы катнашты. Иң зур бүләк – хаҗга юллама Түбән Кама егете Илгиз Нәфиковка тапшырылды, ә Диния нәзарәте кубогына Чаллы командасы ия булды.*






**Рөстәм хәзрәт ШӘЙХЕВӘЛИЕВ,**
Ак мәчетнең имам-хатыйбы, «Ак мәчет» мәдрәсәсе ректоры:

– Быел «Ак мәчет» мәдрәсәсе үзенең 25 еллыгын уздырды. Шул уңайдан, Россиядән һәм 5 чит илдән кунаклар чакырып, халыкара фәнни-гамәли конференция оештырдык. Үзебездән Мирфатыйх Зәкиев, Марсель Бакиров, унлап профессор катнашты. Гыйлем ягына басым ясарга тырышабыз. Бүгенге көндә мәчет-мәдрәсәдә якшәмбе мәктәпләрендә 1200 кеше укый, аларга 80 төркемдә 55 укытучы белем бирә. Мәдрәсәнең көндезге, кичке, читтән торып уку бүлекләрендә 224 шәкерт укый. Үзебезнең студиябез бар, шунда төрле очрашулар оештырабыз, тапшырулар әзерлибез. Яшьләр ихлас булганны ярата. Алтмышка җитсәм дә, яшь булырга тырышам, алар белән футбол, теннис уйныйм… Шуны аңлап, 23 ел буе түзеп яшәгән хатыным Кафиягә рәхмәт.

**Мәрьямбану ХАФИЗ**



иң сөекле кешеләр – вакыт җиткәч тә тизрәк авыз ачарга ашыгучылар.

Минем сабырлыгым тагын ике сәгатькә җитә әле дип, уразаны озынайту изгелек саналмый. Ураза тотучы Раббыма якынаям дип көндезен үзенең теләк-шәһвәтләрен калдырса, кичен Раббыма якынаям дип шул шәһвәтләренә ашыга. Нәтиҗәдә, ач торуы да, ашавы да изгелек булып чыга. Көндезен савапны сабыр итеп җыйса, кичен ризыклана һәм Раббысына шөкер итә.

Раббысы хозурындагы шатлыкка килгәндә, анысы Раббысында руза сәбәпле җыелып

# РАМАЗАН – РУЗА АЕ

**26 майда ахшам вакыты керү белән изге рамазан ае башлана. Шул кичне мәчетләребездә тәравих намазлары укылачак, ә республика ифтары 27 майга билгеләнгән. Аллаһы Тәгалә уразаларыбызны ихлас күңел, җиңеллек белән тотарга насыйп итсә иде.**




Әлбәттә, рамазан ае белән бәйле булган иң төп гыйбадәт ул – фарыз рузасы. Аллаһы Тәгалә: «Кем сездән бу айга иреште – руза тотсын», – диде. («Бәкара», 185). Балигатькә ирешкән, сәламәт, акыл иясе булган һәр мөселман ир һәм мөслимә хатын-кызга рамазан аенда руза тоту фарыз булып тора. Рамазанда руза тоту ислам диненең биш баганасының берседер. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Әй, иман китерүчеләр! Сезгә кадәр булган халыкларга әмер ителгән кебек, сезгә дә рамазан аенда руза тоту фарыз кылынды, шаять ки, сез тәкъвалыкка ирешүчеләрдән булырсыз» («Бәкара», 183).

Аллаһ руза гыйбадәтенә башка гамәлләрдән аермалы буларак махсус саваплар вәгъдә итте. Гадәттә кеше һәр эш өчен, уннан алып җиде йөзгә кадәр савап алырга мөмкин. Ләкин руза бу «лимит» белән чикләнми. Аллаһның Илчесе әйтте: «Адәм баласының һәр гамәле үзе өчен. Бәндә аның өчен уннан алып җиде йөзгә кадәр изгелек-савап алырга мөмкин».

Аллаһы Тәгалә әйтә: «Әмма, рузадан башка. Дөреслектә, рузага әҗерне Мин Үзем бирәм. Бәндә үзенең шәһвәтеннән, ризык һәм эчемлегеннән Минем өчен тыелды». Руза тотучының ике шатлыгы бар, беренчесе авыз ачканда, икенчесе Раббысы белән очрашканда» (Бохари, Мөслим риваятьләре).

Әлхәмдүлилләһ, гыйбадәтнең шатлыгы дөньяда да, ахыйрәттә дә була. Рузаның дөньядагы шатлыкларының берсе – авыз ачканда кичергән сөенечле мизгелләр. Раббыбыз безнең табигатьләребезне ашамлык, эчемлек һәм никах кебек нәрсәләр белән бәйләде. Кешене берникадәр вакытка шул нәрсәләрдән мәхрүм итеп, соңыннан яңадан рөхсәт итсәң, кеше аның өчен куана. Күрергә өйрәнгән хатын-балаларыңны да бераз күрми торсаң сагынасың, соңыннан күрешкәч сөенәсең. 17-18 сәгать авызыңа су да алмый торганнан соң, беренче җимешнең, беренче йотым суның карынга керүе белән күңелләр күтәрелә.

Кеше кояш баерга калган соңгы минутларны ничек түземсезлек белән шатланып көтсә, Аллаһы Тәгалә дә безнең шул көтүләребезне ярата. Хәдистә килгәнчә, Аллаһка килгән әҗерләрне күргәч була. Бәндә ул әҗерләрне Кыяматтә иң кадерле нәрсәләр буларак табыр. Пәйгамбәребез (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм): «Дөреслектә, җәннәттә бер ишек бар. Аңа «Әр-Райян» диеләр. Кыямәт көнендә ул ишектән ураза тотучылар гына керер. Алардан башка ул ишектән һичкем кермәс. «Кайда руза тотучылар?» – дип әйтеләр. Шулвакыт руза тотучылар торып басарлар. Алар җәннәткә кергәч, ишек ябылыр һәм беркем дә ул ишектән кермәс», – диде (Бохари, Мөслим риваятьләре).

Рамазан аенда тоткан рузаның савабы шулкадәр күп, әгәр кеше бер көн рузасын сәбәпсез калдырса, кулыннан ычкынган савапны гомере буе тотып та кайтара алмый. Пәйгамбәребез (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм): «Кем сәбәпсез рамазанның бер көнен ашаса, гомере буе руза тотса да кайтара алмый», – диде (Тирмизи риваяте).

**Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН,**
Түбән Кама районы имам-мөхтәсибе

# Бәраәт кичәсенең кадерен бел!

**Ислам тарихындагы иң мөһим вакыйгаларның берсе – Тәһвилүл кыйбла, ягъни кыйбланың үзгәртелүе шәгъбан аеның 15 нче көненә туры килә. Бу көнне Мәдинәи-Мөнәвәрәнең Бәни Сәләмә мәчетендә Рәсүлуллаһ (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм) өйлә намазы фарызының беренче ике рәкәгатен укыганда вәхи иңгән, намазда килеш ул Кәгъбә тарафына борылган.**



Әлеге вакыйганың шаһиты булган сәхабәләр дә аңа ияреп намазны дәвам иткәннәр (моңа кадәр алар намазны Кодүс Иерусалим шәһәрендәге Әл-Әкъса мәчетенә карап укыган булганнар) Коръәни Кәримдә бу турыда: «Әлбәттә, күрәбез, ий Мөхәммәд галәйһиссәлам, йөзеңне күккә күтәреп торуыңны (Мөхәммәд галәйһиссәлам кыйбла үзгәрмәс борын ук, Ибраһим галәйһиссәлам төзегән Кәгъбатулланың кыйбла булуын тели иде. Шул хакта Җәбраилгә Аллаһ белән сөйләш дигән иде, Җәбраил сөйләшергә вәгъдә биреп китте. Шуннан соң күккә карап Җәбраилне көтәр булды). Әлбәттә, сине үзең теләгән Кәгъбатуллага юнәлдерербез. Менә хәзер йөзеңне юнәлдер мәсҗид Хәрам эчендәге Кәгъбатуллага! Кайда гына булсагыз да йөзләрегезне Кәгъбатуллага юнәлдерегез! Китап әһелләре яһүд һәм нәсара, әлбәттә, беләләр Кәгъбатулланың Аллаһ тарафыннан кыйбла ителгәнлеген. Аллаһ аларның эшләгән эшләреннән гафил түгел», – диелә «Бәкара» сүрәсенең 144 аятендә.

Быел Бәраәт кичәсе 10 майга, ә кичәсенең көне 11 майга туры килә.

Бу кичәдә догалар кабул була, гөнаһлар ярлыкана. Имам Субуки үзенең тәфсирендә болай дип язган: «Дөреслектә, Бәраәт кичәсендә – бер ел эчендә, җомга кичәсендә – бер атна эчендә, ә Кадер кичәсендә гомер буе кылган гөнаһлар гафу ителә». Бу мөбарәк кичәдә:

– хикмәтле рәвештә башкарылачак эшләрнең әһәмиятлеләре сайланып билгеләнә;

– кылган гыйбадәт (намаз, Коръән уку, зикер әйтү) аеруча фазыйләтле һәм саваплы була;

– Пәйгамбәребезгә (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм) тулы шәфәгать (яклау) бирелгән;

– бу кичә илаһи ихсан һәм бәрәкәт белән тулыдыр; мәгъфирәт ягъни ярлыкану кичәседер.

Пәйгамбәребез сөннәте буенча Бәраәт кичәсен дога һәм гыйбадәттә, көнен ураза тотып үткәрергә кирәк. Хәдис-шәрифтә болай диелә: «Шәгъбан аеның унбишенче кичәсе керсә, аны гыйбадәт белән үткәрегез. Көндез исә ураза тотыгыз, чөнки Аллаһы Тәгалә ул кичне кояшның чыгуына кадәр дөнья галәменә рәхмәт күзе белән карар һәм боерыр: «Тәүбә һәм истигъфар итүче булса, аны гафу итәм. Ризык сораучы булса, аңа ризык бирәм. Авыруга дучар булса, аңа саулык-сәламәтлек бирәм. Бармы андый кешеләр?» – дип әйтер (Ибн Мәҗә).

Бәраәт кичәсендә махсус намаз уку мөстәхәб санала. Моның турында тапшырылган хәдисләр зәгыйфь булсалар да, изге гамәлләр кылуга килгәндә, зәгыйфь хәдисләргә нигезләнергә мөмкин, диелә «Шура» альманахының 16 нчы санында һәм бу төнне гыйбадәттә үткәргән өчен нинди саваплар язылуы бәян ителә. Күп кенә риваятьләрдә «саләтүл-хайр» дип аталучы әлеге намазның йөз рәкәгатьтән торуы һәм һәр рәкәгатьтә «Әл-Фатиха» сүрәсеннән соң ун тапкыр «Әл-ихлас» сүрәсе укылырга тиешлеге хәбәр ителә. Аллаһы Тәгалә бу намазны укыган бәндәсе янына җитмеш мең фәрештәсен җибәрер, алар аның киләсе елга кадәр алачак савапларын язып, гөнаһларын җуеп, дәрәҗәсен күтәреп торырлар. Шул кеше киләсе ел җиткәнче вафат булса, шәһит кебек китәр. Аның бар кылган һәм кылачак намазлары кабул булыр.

# Балаларыбыз өчен кыла торган дога



Йә, Раббым, балаларыбыз тәкъва мөселманнардан, хәерле мөселманнардан, Үзең яраткан бәндәләрдән булсалар иде. Үзләре сау-сәламәт, күңелләре саф, йөзләре нурлы, диннәре дөрес, иманнары көчле булса иде.

Йә, Раббым, Үзеңә итагать итүчеләрдән, гыйбадәт кылучылардан, фарыз һәм сөннәт гамәлләрен үтәүчеләрдән, гыйбрәт алучылардан, канәгать булучылардан, нигъмәтләреңнең кадерен белүчеләрдән, күп зикер кылучылардан булсалар иде.

Йә, Раббым, аларга тәүфыйк, һидаять, зирәк акыл, гыйлем бир. Ислам динен куәтләүче, оятны белүче, әхлаклы, әдәпле, тәрбияле, намуслы, тырыш, максатчан, эчкерсез, юмарт, тыйнак, гадел, эшчән, уңган булсалар иде. Укуларында ачык зиһен, тел байлыгы, тел ачкычлары бир. Укытучыларына, остазларына, иптәшләренә, барча кешеләргә күркәм итеп, сөйкемле итеп күрсәт. Әчке күңелләре, тышкы кыяфәтләре һәрвакыт күркәм булса иде.

Йә, Раббым, әти-әниләрен, олыларны хөрмәт итеп, кечеләргә шәфкатьле, мәрхәмәтле, кешеләргә игелекле, ярдәмчел булсыннар. Чисталыкны, пакьлекне яратсыннар, сафлыкка омтылсыннар.

Йә, Раббым, кайгы-хәсрәт китермәсеннәр, күз яшьләре түктермәсеннәр. Балаларыбызга хәерле хәләл кәсепләр, хәләл сөт имгән, хәләл ризык белән ризыкланган иманлы хәерле парларын насыйп ит, салих вә тәкъва бәндәләреңә дус ит.

Балаларыбыз безнең йөз аклыгы булса иде. Аларга хәерле озын гомер бир, Раббым. Аларның куанычларын күреп, шатлык-сөенечләр белән яшәргә насыйп ит. Әмин.

*(Социаль челтәрдән)*

# Бөгелмә шәһәре өчен май аена намаз вакытлары

| МИЛАДИ | ТАҢ БЕЛЕНӘ | ИРТӘНГЕ | КОЯШ ЧЫГА | ЗӘВӘЛ | ӨЙЛӘ | ИКЕНДЕ | АХШАМ | ЯСТУ | ҺИЖРИ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 дүш | 00:53 | 02:20 | 03:50 | 11:25 | 12:00 | 16:36 | 19:02 | 21:17 | 5 |
| 2 сиш | 00:47 | 02:18 | 03:48 | 11:25 | 12:00 | 16:37 | 19:04 | 21:20 | 6 |
| 3 чәр | 00:41 | 02:16 | 03:46 | 11:25 | 12:00 | 16:38 | 19:06 | 21:24 | 7 |
| 4 пән | 00:35 | 02:14 | 03:44 | 11:25 | 12:00 | 16:40 | 19:08 | 21:28 | 8 |
| **5 җом** | **00:28** | **02:12** | **03:42** | **11:25** | **12:00** | **16:41** | **19:10** | **21:32** | **9** |
| 6 шим | 00:20 | 02:10 | 03:40 | 11:25 | 12:00 | 16:42 | 19:11 | 21:35 | 10 |
| 7 якш | 00:11 | 02:08 | 03:38 | 11:25 | 12:00 | 16:43 | 19:13 | 21:39 | 11 |
| 8 дүш | 00:01 | 02:06 | 03:36 | 11:25 | 12:00 | 16:44 | 19:15 | 21:44 | 12 |
| 9 сиш | 23:47 | 02:04 | 03:34 | 11:25 | 12:00 | 16:45 | 19:17 | 20:47 | 13 |
| 10 чәр | 01:32 | 02:02 | 03:32 | 11:25 | 12:00 | 16:46 | 19:19 | 20:49 | 14 |
| 11 пән | 01:30 | 02:00 | 03:30 | 11:25 | 12:00 | 16:47 | 19:21 | 20:51 | 15 |
| **12 җом** | **01:28** | **01:58** | **03:28** | **11:25** | **12:00** | **16:48** | **19:22** | **20:52** | **16** |
| 13 шим | 01:26 | 01:56 | 03:26 | 11:25 | 12:00 | 16:49 | 19:24 | 20:54 | 17 |
| 14 якш | 01:25 | 01:55 | 03:25 | 11:25 | 12:00 | 16:50 | 19:26 | 20:56 | 18 |
| 15 дүш | 01:23 | 01:53 | 03:23 | 11:25 | 12:00 | 16:51 | 19:28 | 20:58 | 19 |
| 16 сиш | 01:21 | 01:51 | 03:21 | 11:25 | 12:00 | 16:52 | 19:29 | 20:59 | 20 |
| 17 чәр | 01:20 | 01:50 | 03:20 | 11:25 | 12:00 | 16:53 | 19:31 | 21:01 | 21 |
| 18 пән | 01:18 | 01:48 | 03:18 | 11:25 | 12:00 | 16:54 | 19:33 | 21:03 | 22 |
| **19 җом** | **01:16** | **01:46** | **03:16** | **11:25** | **12:00** | **16:55** | **19:34** | **21:04** | **23** |
| 20 шим | 01:15 | 01:45 | 03:15 | 11:25 | 12:00 | 16:56 | 19:36 | 21:06 | 24 |
| 21 якш | 01:13 | 01:43 | 03:13 | 11:25 | 12:00 | 16:57 | 19:38 | 21:08 | 25 |
| 22 дүш | 01:12 | 01:42 | 03:12 | 11:25 | 12:00 | 16:58 | 19:39 | 21:09 | 26 |
| 23 сиш | 01:10 | 01:40 | 03:10 | 11:25 | 12:00 | 16:59 | 19:41 | 21:11 | 27 |
| 24 чәр | 01:09 | 01:39 | 03:09 | 11:25 | 12:00 | 17:00 | 19:42 | 21:12 | 28 |
| 25 пән | 01:08 | 01:38 | 03:08 | 11:25 | 12:00 | 17:00 | 19:44 | 21:14 | 29 |
| **26 җом** | **01:06** | **01:36** | **03:06** | **11:25** | **12:00** | **17:01** | **19:45** | **21:15** | **30** |
| 27 шим | 01:05 | 01:35 | 03:05 | 11:25 | 12:00 | 17:02 | 19:47 | 21:17 | 1 |
| 28 якш | 01:04 | 01:34 | 03:04 | 11:26 | 12:00 | 17:03 | 19:48 | 21:18 | 2 |
| 29 дүш | 01:03 | 01:33 | 03:03 | 11:26 | 12:00 | 17:04 | 19:49 | 21:19 | 3 |
| 30 сиш | 01:02 | 01:32 | 03:02 | 11:26 | 12:00 | 17:05 | 19:51 | 21:21 | 4 |
| 31 чәр | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 11:26 | 12:00 | 17:05 | 19:52 | 21:22 | 5 |
| ЧИСЛО | ОКОНЧАНИЕ СУХУРА | УТРЕННИЙ | РАССВЕТ | ЗЕНИТ | ЗУХР | АСР | МАГРИБ | ИША | ХИДЖРИ |

**10 май** – Бәраәт кичәсе
**27 май** – рамазан аеның беренче көне

**Апрель азагында Гаилә мәчете каршындагы «Ислам дине нигезләре» курсларында укучыларның чыгарылыш кичәсе булды. 39 кардәшебез Татарстан мөфтие урынбасары, Гаилә мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин кулыннан курсларны тәмамлаганлыкка таныклык алды.**



# Гаилә мәчете каршындагы курсларда чыгарылыш кичәсе узды

Курсларда җәмгысе 300 гә якын шәкерткә 30 лап остаз-абыстай гыйлем бирә. «Пәйгамбәребезнең (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм) хәдисендә китерелгәнчә, мөселман кешегә бишектән ләхеткәчә гыйлем алу тиеш, – дип башлады үзенең котлау чыгышын Рөстәм хәзрәт Хәйруллин. – Менә безнең мәчет каршындагы курсларда да төрле яшьтәге шәкертләр гыйлем ала: иң бәләкәй шәкерткә – 3,5 яшь, иң өлкәненә – 86. Кем гыйлем юлын сайлый – Аллаһы Тәгалә аның җәннәткә юлын җиңеләйтер, ди. Төрле сәбәп табып дәресләрне калдырырга була. Сез инде изге юлны сайлагансыз икән, беркүк читкә тайпылмагыз. Дәрес, кыенлыклар бар, сыйныф бүлмәләре җитми. Без моны беләбез, борчылабыз, кыенлыктан чыгу юлларын эзлибез. Менә, Аллаһ рәхмәтен салып, мәчет ишегалдында мәдрәсә салырга дигән ният белән йөрибез. Ә инде үзләренең вакытлары белән санлашмыйча, матди файда өмет итмичә, булган гыйлемнәрен сезнең белән бүлешүче остаз-абыстайларга Аллаһы Тәгалә савапларын язсын һәм язар да, иншаллаһ».

Аннары Рөстәм хәзрәт шәкертләргә мәчет каршындагы өчьеллык курсларны тәмамлаганлыкка таныклыклар, ә мөгаллимнәргә Рәхмәт хатлары тапшырды. Чыгарылыш тантанасы бәйрәм табыны артында дәвам итте. Шәкертләр гыйлем алу мөмкинлеге тудырган өчен мәчетнең имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллинга, остазларына һәм мәчет коллективына рәхмәтләрен җиткерделәр.

**Мәрьямбану ХАФИЗ**



# Что делать, если не успел возместить пост до наступления рамадана?



